**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БОЛЬШЕКАБАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул.Южная, дом 1, село. Малые Кабаны
422623, Телефон/факс(84378)4-22-02
E-mail: Bkab.La@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ КАБАН ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кәньяк урамы,1 нчы йорт,
Рече Кабан авылы,
422623 Телефон/факс(84378)4-22-02
E-mail: Bkab.La@tatar.ru

**2025 елның 3 декабре** **12 номер**

# КАРАР

## «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Олы Кабан авыл җирлеге территориясендә пиротехника әйберләрен куллануны тәртипкә салу чаралары турында» Олы Кабан авыл җирлеге башкарма комитетының 2019 елның 11 декабрендәге 13 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

Яңа ел бәйрәм чараларының, гражданнарның гомеренең һәм сәламәтлегенең, физик һәм юридик затларның, дәүләт яисә муниципаль мөлкәтенең янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү максатларында, «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы Федераль законның 30 статьясы һәм «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1993 елның 18 маендагы 1866-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының 25 статьясы, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә янгынга каршы махсус режим билгеләү турында» 2019 елның 05 декабрендәге 1103 номерлы карары нигезендә КАРАР ИТӘМ:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Олы Кабан авыл җирлеге территориясендә пиротехника әйберләрен (фейерверк күрсәтүләрен) куллануны тәртипкә салу чаралары турында» Олы Кабан авыл җирлеге башкарма комитетының 2019 елның 11 декабрендәге 13 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Карарның 4 пунктын түбәндәге абзац белән тулыландырырга:

«50 метрдан артык биеклектәге салют һәм фейерверклар уздырганда, шулай ук җир яисә су өслегенә һава алымнары полосаларын проекцияләү чикләрендә, салют һәм фейерверклар биеклегенә карамастан, һава киңлеген куллану Россия

Федерациясе һава хәрәкәтен оештыруның бердәм системасы оператив органы рөхсәте белән гамәлгә ашырыла (алга таба - вәкаләтле орган).

Фейерверк уздыру өчен вәкаләтле органнан рөхсәт алырга кирәк. Язма рөхсәттән башка муниципаль берәмлек территориясендә фейерверк уздыру тыела».

2.Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында-http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Олы Кабан авыл җирлегенең махсус мәгълүмати стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче вазифасын башкаручы Р.Г. Гыйниятуллин